| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

---

Р Е Ш Е Н И Е　　　　　　　　　　КАРАР

2019 елның 22 гыйнвары　　　　　　　　　　№ 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан 2016 елның 3 октябрендә 31 нче санлы карар белән расланган “Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турындагы” муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-исәп органнарының гомуми оештыру принциплары һәм эшчәнлеге” Федераль законының 7нче маддәсенә үзгәрешләр кертү турындагы” 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль законына һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” Федераль законның 13нче маддәсе һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан 2016 елның 3 октябрендә 31 нче санлы карар белән расланган “Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы “Сарабиккол авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау турындагы” муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

6нчы бүлектәге 6.5 пунктны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

«6.5 Гражданин муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары хезмәткәрләре белән якын туган яисә сыйфатында (әти-әниләр ир-хатын, балалар ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук ир-хатыннарының ир туганнары, кыз туганнары, әти-әниләре, ир-хатыннарының балалары, балаларының ир-хатыннары) булганда, муниципаль берәмлек органына рәис, рәис урынбасары һәм муниципаль берәмлектә контроль-исәп органы аудиты буларак, ә муниципаль хезмәткәр рәис, рәис урынбасары һәм муниципаль берәмлектә контроль-исәп органы аудиты вазифаларын башкара алмый”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авылы җирлегендәге мәгълүмати стендларда һәм Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Лениногорск муниципаль районы
“Сарабиккол авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы

Г.Р.Гаделшина